**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 13 гыйнвар № 6

г. Казань

Чит илдәге һәм үз илебездәге медицина оешмаларында галимнәрнең һәм аспирантларның стажировкаларын оештыруга медицина һәм фармацевтика белеме буенча һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы югары белем бирүче мәгариф оешмаларына Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантын гамәлгә кую турында

Медицина һәм фармацевтика белеме буенча һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы югары белем бирүче мәгариф оешмалары эшчәнлеген стимуллаштыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Чит илдәге һәм үз илебездәге медицина оешмаларында галимнәрнең һәм аспирантларның стажировкаларын оештыруга медицина һәм фармацевтика белеме буенча һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы югары белем бирүче мәгариф оешмаларына Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантын гамәлгә куярга.

2. Чит илдәге һәм үз илебездәге медицина оешмаларында галимнәрнең һәм аспирантларның стажировкаларын оештыруга медицина һәм фармацевтика белеме буенча һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы югары белем бирүче мәгариф оешмаларына Татарстан Республикасы Хөкүмәте гранты турындагы нигезләмәне (карарга теркәлә) расларга.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына 30 көн эчендә:

чит илдәге һәм үз илебездәге медицина оешмаларында галимнәрнең һәм аспирантларның стажировкаларын Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантын бирү буенча эксперт комиссиясен төзергә;

түбәндәгеләрнең формаларын расларга:

чит илдәге һәм үз илебездәге медицина оешмаларында галимнәрнең һәм аспирантларның стажировкаларын оештыруга медицина һәм фармацевтика белеме

буенча һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы югары белем бирүче мәгариф оешмаларына Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантын алуга гариза;

чит илдәге һәм үз илебездәге медицина оешмаларында галимнәрнең һәм аспирантларның стажировкаларын оештыруга медицина һәм фармацевтика белеме буенча һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы югары белем бирүче мәгариф оешмаларына Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантын алуга мотивлаштыру хаты;

чит илдәге һәм үз илебездәге медицина оешмаларында галимнәрнең һәм аспирантларның стажировкаларын оештыруга медицина һәм фармацевтика белеме буенча һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы югары белем бирүче мәгариф оешмаларына Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантын бирү турында шартнамә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\6.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 13 гыйнвар, 6 нчы карары белән расланды

**Чит илдәге һәм үз илебездәге медицина оешмаларында галимнәрнең һәм аспирантларның стажировкаларын оештыруга медицина һәм фармацевтика белеме буенча һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы югары белем бирүче мәгариф оешмаларына Татарстан Республикасы Хөкүмәте гранты турында нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә чит илдәге һәм үз илебездәге медицина оешмаларында галимнәрнең һәм аспирантларның стажировкаларын оештыруга медицина һәм фармацевтика белеме буенча һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы югары белем бирүче мәгариф оешмаларына Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын (алга таба – грантлар) бирү тәртибен билгели.

Грантны бирү максаты – чит илдәге һәм үз илебездәге медицина оешмаларында галимнәрнең һәм аспирантларның стажировкаларын оештыруга медицина һәм фармацевтика белеме буенча һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы югары белем бирүче мәгариф оешмаларына дәүләт ярдәме күрсәтүне көчәйтү.

1.2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр файдаланыла:

грант – чит илдәге һәм үз илебездәге медицина оешмаларында галимнәрнең һәм аспирантларның стажировкаларын оештыру өчен, әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда грант алучыга Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан бушлай һәм кире кайтарылмыйча бирелә торган субсидия;

грант бирүче – грант бирүгә вәкаләтле орган йөзендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты;

гран бирүгә вәкаләтле орган – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;

медицина белеме бирү оешмалары – Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, медицина һәм фармацевтика белеме буенча һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы югары белем бирүче мәгариф оешмалары;

грантка дәгъва итүчеләр – әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә һәм критерийларга туры килүче медицина белеме бирү оешмалары;

грант алучылар – грантлар бирелгән медицина белеме бирү оешмалары;

грант алуга конкурс – әлеге Нигезләмә нигезендә үткәрелә торган грантка дәгъва итүчеләрне сайлап алуга бәйле чара;

конкурс документлары – грант алуга конкурста катнашу өчен кирәкле документлар;

эксперт комиссиясе – грант бирүгә вәкаләтле орган тарафыннан төзелгән

грантлар бирү буенча комиссия.

1.3. Грант алуга конкурс әлеге Нигезләмәнең 4.1 нче пункты нигезендә грант бирүгә вәкаләтле органның рәсми сайтында мәгълүмат урнаштыру юлы белән игълан ителә.

1.4. Грант алучылар эксперт комиссиясе тарафыннан конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

## 2. Грантка дәгъва итүчеләргә таләпләр

2.1. Грантка дәгъва итүчеләр түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

медицина һәм фармацевтика белеме буенча һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы югары белем бирүче мәгариф оешмасы яки әлеге югары белем бирү оешмасының филиалы булу һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан булу;

грант алуга конкурста катнашу вакытында Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә алынган белем бирү эшчәнлеген алып бару хокукына лицензия булу;

грант алуга конкурста катнашу вакытында Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә алынган белем бирү эшчәнлегенә дәүләт аккредитациясе турындагы шаһәдатнамәгә ия булу;

Россия Федерациясе законнарында күздә тотылган очракларда, грант алуга конкурста катнашу вакытында грант алуга конкурста катнашу өчен гамәлгә куючының рөхсәтнамәсе булу.

## 3. Эксперт комиссиясе

3.1. Эксперт комиссиясе составы, эксперт комиссиясе утырышлары графигы, аларны үткәрү вакыты һәм урыны грантны бирүгә вәкаләтле орган тарафыннан расланa.

3.2. Эксперт комиссиясен рәис җитәкли. Рәис эксперт комиссиясе эшчәнлеге белән гомуми җитәкчелек итә, аның утырышларын алып бара, эксперт комиссиясе кабул иткән карарларны раслый, грант алуга конкурста җиңүчеләрне игълан итә, эксперт комиссиясе утырышы беркетмәсен раслый, эксперт комиссиясенә йөкләнгән бурычларның үтәлүе өчен шәхсән җаваплылык тота. Рәис булмаган очракта, аның вазыйфаларын һәм хокукларын урынбасары башкара.

3.3. Эксперт комиссиясе конкурс документлары кабул ителмәгән грантка дәгъва итүчеләр белән үзара язышмый. Тапшырылган конкурс документлары рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

3.4. Эксперт комиссиясе утырышы, анда комиссия әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, хокуклы санала.

3.5. Эксперт комиссиясе карарлары ачык тавыш бирү юлы белән, утырышта катнашучы эксперт комиссиясе әгъзалары тавышларның күпчелеге нигезендә кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә. Тавышлар тигез булган очракта, рәис тавышы хәлиткеч санала. Эксперт комиссиясе әгъзасы кабул ителгән карар белән

риза булмаса, аның теләге буенча беркетмәдә аерым фикер күрсәтелә. Эксперт комиссиясенең конкурста җиңүчеләрне билгеләү буенча утырышы конкурс документларын тапшыру вакыты узган көннән 25 көн эчендә үткәрелә.

3.6. Эксперт комиссиясе әгъзасы, әгәр ул заявка тапшырган грантка дәгъва итүченең гамәлгә куючысы, әгъзасы, хезмәткәре булса, автор, эксперт булса, грантка дәгъва итүче турында сүз алып баруда катнаша алмый, һәм эксперт комиссиясе әгъзасы бу хакта рәискә язмача хәбәр итәргә тиеш.

3.7. Эксперт комиссиясе утырышлары беркетмәләрен эксперт комиссиясе секретаре алып бара. Утырыш беркетмәсенә эксперт комиссиясе секретаре тарафыннан имза куела, һәм эксперт комиссиясе утырышын үткәргән көннән өч көн эчендә беркетмә эксперт комиссиясе рәисе тарафыннан раслана.

3.8. Эксперт комиссиясе утырышлары беркетмәләре, эксперт комиссиясе рәисе аларны раслаган көннән соң, биш ел дәвамында грант бирүчедә саклана.

## 4. Конкурс процедураларын үткәрү тәртибе һәм конкурс документлары исемлеге

4.1. Грант алуга конкурсны үткәрү турындагы игълан грант бирүгә вәкаләтле органның рәсми сайтында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә www.alga.tatar.ru адресы буенча, грант алуга конкурс үткәрүнең күздә тотылган вакытына кадәр кимендә 30 календарь көн алдан урнаштырыла. Игълан грант алуга конкурсны үткәрү вакыты, урыны һәм тәртибе, конкурс документларын тапшыру башланган һәм тәмамланган вакыт турындагы мәгълүматларны үз эченә алырга тиеш.

4.2. Конкурс документларын тапшыру вакытлары грант алуга конкурсны үткәрү турындагы игъланда билгеләнә һәм тиешле игълан бастырылган көннән башлап санала. Грант алуга конкурста катнашу өчен бер гариза да тапшырылмаган очракта, конкурс үткәрелмәгән булып санала. Конкурс документларын бер грантка дәгъва итүче тапшырган очракта, әлеге конкурс документлары әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә карап тикшерелә һәм бәяләнә.

4.3. Грант алуга конкурста катнашу өчен грантка дәгъва итүче конкурс документлары комплектын «Грант алуга гариза» дигән язулы ябыштырылган конвертта грант алуга конкурсны үткәрү турындагы игъланда күрсәтелгән вакытта 420111, Казан шәһәре, Дзержинский урамы, 3 нче йорт, 110 кабинет адресы буенча җибәрә. Гаризаларны электрон рәвештә кабул итү күздә тотылмаган.

4.4. Конкурс документлары килгән көнне грант бирүче тарафыннан кабул ителә һәм теркәлә.

4.5. Грант алуга конкурста катнашучы өчен, грантка дәгъва итүче түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга тиеш:

әлеге Нигезләмәнең 2.1 нче пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килергә;

грант бирүгә вәкаләтле органга түбәндәге конкурс документларын тапшырырга:

грант бирүгә вәкаләтле орган раслаган форма буенча грант алуга гаризаны;

Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә расланган гамәлгә кую документлары күчермәләрен;

Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бирелгән белем бирү эшчәнлеген алып бару хокукына гамәлдәге лицензия күчермәсен (кушымтасы белән);

Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бирелгән белем бирү эшчәнлегенә дәүләт аккредитациясе турындагы гамәлдәге шаһәдатнамә күчермәсен (кушымтасы белән);

грант бирүгә вәкаләтле орган раслаган форма буенча мотивлаштыру хаты;

Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган очракларда, грант алуга конкурста катнашу өчен гамәлгә куючы рөхсәтнамәсе.

4.6. Грант бирүгә вәкаләтле орган түбәндәге очракларда конкурс документларын кабул итүдән һәм теркәүдән баш тарта:

грантка дәгъва итүченең конкурс документларының тулы булмаган комплектын кертүе;

грантка дәгъва итүченең белә торып дөрес булмаган мәгълүматлар тапшыруы ;

грантка дәгъва итүченең документларын кире кайтару турындагы үтенеч белән язма рәвештә мөрәҗәгать итүе.

4.7. Грант бирүгә вәкаләтле орган конкурс документларын алган көннән өч эш көне эчендә конкурс документларын эксперт комиссиясе карап тикшерүенә җибәрә.

## 5. Конкурс документларын бәяләү критерийлары һәм тәртибе

5.1. Эксперт комиссиясе грантка дәгъва итүчеләрнең конкурс документларын түбәндәге критерийлар буенча бәяли:

5.1.1. Формасын анализлау: әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килү (0 – 5 балл).

5.1.2. Эчтәлеген анализлау:

стажировка барышында өйрәнелгән технологияне Татарстан Республикасы территориясендә кертү перспективалары:

технологияне белем бирү, фәнни, клиник процессларга кертү өчен шартлар булу (0 – 5 балл);

технологиягә башка хезмәткәрләрне укыту-өйрәтү мөмкинлеге (0 – 5 балл);

технологияне кулланып, яңа программалар, ысуллар, продуктлар эшләү мөмкинлеге (0 – 5 балл);

коммерцияләштерү мөмкинлеге (кулланучыларга түләүле нигездә тәкъдим ителергә мөмкин булган яңа белем бирү программалары, дәвалау технологияләре, фәнни продуктлар эшләү) (0 – 5 балл);

партнерлар өчен актуальлеге, Татарстан Республикасы өчен социаль эффект (0 – 5 балл).

5.2. Эксперт комиссиясе конкурс документларын бәяләү һәм тавыш бирү нигезендә иң күп балл җыйган грантка дәгъва итүчеләрне сайлап ала.

5.3. Конкурс нәтиҗәләре биш көн эчендә конкурста җиңүчеләр игътибарына җиткерелә һәм грант бирүгә вәкаләтле органның рәсми сайтында урнаштырыла.

## 6. Грант бирү турында шартнамә төзү

6.1. Грант бирүгә вәкаләтле орган әлеге Нигезләмәнең 5.3 нче пункты нигезендә конкурс йомгаклары турында мәгълүмат урнаштырган көннән соң календарь көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә грант алучы белән грант бирү турында шартнамә төзи.

6.2. Грант бирү турында шартнамә формасы грант бирүгә вәкаләтле орган тарафыннан раслана. Шартнамә ике якның хокуклары һәм бурычлары турындагы, гранттан файдалану тәртибе хакындагы, грант бирүгә вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан грант алучының грантны бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә тикшерү үткәрүгә грант алучының ризалыгы турындагы нигезләмәләрне үз эченә алырга тиеш.

## 7. Грантны бирү һәм аннан файдалану

7.1. Грант бирүгә вәкаләтле орган грант бирү турындагы шартнамәдә билгеләнгән вакытта акчаны грант алучыга бирә.

7.2. Грант алучы гранттан бары тик әлеге Нигезләмәдә һәм грант бирү турындагы шартнамәдә билгеләнгән максатларда гына файдалана.

7.3. Грант акчасыннан максатчан файдаланмаган, грант бирү турындагы шартнамә шартларын бозу факты ачыкланган яки гранттан файдалану хакында хисап тапшырмаган очракларда, грант бирүгә вәкаләтле орган шартнамәне өзәргә һәм грант буенча бирелгән барлык акчаларны кире кайтаруны таләп итәргә хокуклы.

7.4. Акчалар грант алучының исәп-хисап счетына грант бирү турындагы шартнамәдә билгеләнгән күләмдә һәм шартлар нигезендә күчерелә.

7.5. Россиядәге һәм чит илдәге белем бирү оешмаларында өч айга кадәр вакытлы стажировкалар грант акчасыннан финанслана.

7.6. Грант күләме стажировкага, чит илдәге белем бирү оешмасында каралган медицина иминиятләштерүенә, Казан шәһәреннән стажировка урынына кадәр тимер юл яки авиация транспортында бару һәм кайтуга, шулай ук стипендия бирүгә чыгымнарны түләүне күздә тота. Виза алуга бәйле чыгымнар грант алучының үз акчасы исәбеннән түләнә.

7.7. Грант бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне, гранттан максатчан файдалануны тикшерүдә тоту грант бирүче һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 8.1 нче пунктында күрсәтелгән хисап документларын тапшыру көненнән соң утыз көн эчендә мәҗбүри тикшерү үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла. Тикшерү нәтиҗәләре буенча грант бирүченең һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының уртак акты төзелә, һәм ул биш көн эчендә грант алучыга җибәрелә.

## 8. Хисаплылык

8.1. Грант алучы грант бирүчегә грант акчасыннан файдалану турында агымдагы һәм йомгак язма хисап кертә. Хисапларга мәҗбүри рәвештә түбәндәгеләр теркәлә:

стажировка өчен түләүне раслый торган документлар, шулай ук стажировканы уңышлы үткәнне раслый торган белем алу турында документ;

чит илдәге белем бирү оешмасы белән каралган медицина иминиятләштерүе күчермәсе;

Казан шәһәреннән стажировка урынына кадәр тимер юл яки авиация транспортында бару һәм кайту чыгымнарын дәлилли торган документлар.

8.2. Агымдагы һәм йомгак язма хисапларның формалары һәм аларны кертү вакытлары грант бирү турындагы шартнамә нигезендә билгеләнә.

## 9. Грантларны кайтару тәртибе

9.1. Грантның грант алучы тарафыннан хисап финанс елында файдаланылмый калган өлеше грант бирүчегә кире кайтарылырга тиеш.

Грантлар шулай ук түбәндәге очракларда кайтарылырга тиеш:

грант алучының гранттан баш тартуы;

грант алуга конкурста катнашу вакытында һәм грантны гамәлгә ашыру вакытында грант алучының үзе турында белә торып дөреслеккә туры килмәгән, тулы булмаган яки ялган мәгълүматлар тапшыру фактын ачыклау;

грант бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен бозу, гранттан максатчан файдаланмау;

әлеге Нигезләмәдә һәм грант бирү турындагы шартнамәдә күздә тотылган вазыйфаларны грант алучының үтәмәве.

9.2. Әлеге Нигезләмәнең 9.1 нче пунктында күрсәтелгән очраклар ачыкланса, грант бирүче грант алучыга биш көн эчендә, акчаны күчерү өчен банк исәбен күрсәтеп, грантны кайтарырга кирәк булу турында язма рәвештә хәбәр җибәрә.

9.3. Грант бирүче тарафыннан бирелгән акчалар бирелгән грантларны кайтарырга кирәк булу турында хәбәр алган көннән 5 банк көне эчендә кайтарылырга тиеш.

9.4. Грант акчасын үз ихтыяры белән кайтарудан баш тартсалар, әлеге акча законнар нигезендә мәҗбүри түләттерелергә тиеш.

___